# 8 нче сыйныфта татар теленнән язма эшләр

1. ***Сүз төркемнәре темасына диктант.***

**Ак әби**

Акәби дөнья куйды! Карт, бик карт иде ул Акәби. Шулай да аның үлеменә бәйләнешле вакыйгалар безнең күңелләрдә мәңге җуелмас яра булып калды.

Ак әбигә ничә яшь, бу дөньяда күпме яшәгән ул — моны беркем дә тәгаен генә белми иде. Хәтта аның чын исеме дә онытылган. Безнең бабайлар заманында ук инде аның чәчләре, йөзе, кигән киеме, башындагы яулыгы, киез каталары, тула оеклары — һәммәсе актан булган. Күрәсең, шуңадыр, авыл халкы аңа Акәби дип кенә эндәшә, хөрмәт итә иде. **Өлкәннәр үзләрен аның алдында никтер бурычлы саныйлар.** Әбекәй инде күптән эшләрлек хәлдә булмаса да, аның тамагы тук, өс-башы ак-пакь, өе җылы була иде. Күрше-тирә халкы мал суямы, май язамы яисә тәмлерәк мич ашы пешерәме — Акәбин өлешсез калдырмый. (111 сүз)

*(Р. Хафизовадан)*

**Бирем.**

**Билгеләнгән җөмләне сүз төркемнәре һәм җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерергә.**

2. ***Изложение***

**Күтелмәгән сорау**

Рәсим күтәрелеп караган иде, алгы партада утыручы Илһамның ручкасына күзе төште. Гади генә дә түгел, бизәкләп, сырлап ясалган иде ул. Тәрәзәдән сузылган кояш нурларында алтындай елык-елык килә. Уйнаклаган нурлар Рәсимне: «Синең андый ручкаң юк»,— дип үчеклиләр сыман иде.

Тора-бара әлеге ручка малайның тәмам тынычлыгын алды. Аңа карап утыра торгач, кыңгырау шалтыраганын да ишетмәде. Малайлар ишектән йөгереп чыга башлагач кына кайда утыруын абайлап алды.

Әнә Илһам да, ручкасын кесәсенә салып, ишеккә юнәлде. Рәсим аның артыннан көнләшеп карап калды. Шул минутта күңелендә бер уй кузгалды. Әлеге ручканы

үзенеке итү теләге иде ул.

Тәнәфес вакытында да, кыңгырау шалтырап икенче дәрескә кереп утыргач та, малай гел шул хакта баш ватты. Дәрес буена күзе алдагы партада — нидер сизенгәндәй Илһам кулына сыенган ручкада булды. Аңа караган саен, теге кара теләк арта гына барды.

Дәресләр тәмамлануын белдереп, янә кыңгырау тавышы бирелүгә, Рәсим ашыкмый-кабаланмый урыныннан торды. Сумкаларына дәфтәр, китапларын тутыру белән мәшгуль булган Илһам ручкасының юкка чыкканын сизми дә калды. Рәт арасыннан узганда, Рәсим үзенең тынычлыгын алган ручканы эләктергән иде инде. Ничек шулай оста, тиз эләктергәндер, соңыннан үзе дә гаҗәпләнде ул моңа. Аны-моны уйламаган Илһам, сумкасын күтәреп, сыйныф бүлмәсеннән чыгып китте.

Рәсимнән дә бәхетле малай юк иде бу минутларда. Бизәкле ручка аның кесәсенә кереп кунаклаган иде.

Өйләренә дә алтын кош тоткандай очынып кайтып керде. Кесәсеннән алып, ручканы әйләндереп-тулгандырып карарга кереште. Бигрәкләр дә матур, язарга да ипле икән. Шушы ручканы үзенеке итүенә гел сөенеп, шатланып йөрер кебек иде малай. Тик куанычы озакка бармады.

Барысына да сеңлесе Илгизә сәбәпче булды. Абыйсының кулындагы ручканы кай арада күреп алган диген. Янәшәсенә килеп басты да шәрран ярып сорап та куйды:

— Ай, нинди матур ручка. Кайдан алдың аны, абый?

Бу көтелмәгән сорауга ни-нәрсә дип тә җавап бирә алмады Рәсим. Алгы бүлмәдән әнисе килеп чыкты. Ул да, улы кулындагы ручканы күреп, шул ук сорауны кабатлады. Рәсим тәмам коелып төште. Әле бая гына ручканы үзенеке итүенә сөенеп туя алмаган иде. Хәзер җавап бирә алмый, башын аска иеп тик басып тора. Йөзе комач кебек кызыл.

— И-и-и, улым, күреп торам, кеше әйберенә тигәнсең. Кара аны, иясенә илтеп бир,— диде әнисе һәм, кисәк кенә борылып, бүлмәдән чыгып та китте.

Рәсим янә учына күз салды. Ручка элеккечә балкып күренми иде инде. (350 сүз)

*(Р. Гыйззәтуллиннан)*

3. ***Җөмлә темасына контроль диктант.***

**Нәрсә бүләк итәргә?**

Бәйрәмнәрдә, туган көннәрдә бер-береңә бүләк бирү — яхшы гадәт. Нинди бүләк һәм бүләкне ничек бирергә? Тантана көнне бүләкне иртә белән бирү күңелле. Бүләкне алу белән читкә алып куймыйлар. Шунда ук төргәк кәгазеннән ачып карыйлар. Кызлар өчен иң яхшы бүләк— чәчәкләр. Шулай ук китап та әйбәт бүләк булып исәпләнә. Үзең ясаган әйберләрне бүләк итү дә күңелле. Мәсәлән, агачтан кисеп эшләнгән фигуралар, яки шигырь язып, рәсем ясап бирергә мөмкин. Кемгә бүләк итәсең, ул кеше нәрсә белән кызыксына, шуны истә тотарга, аның зәвыгы турында онытмаска кирәк. Бүләкне зурлыгына карап бәяләмиләр. «Инә дә бүләк, дөя дә бүләк», — ди бит халык мәкале. *(96 сүз.) (Матбугат битләреннән)*

**Бирем.**

**Івариант.** Өченче җөмләне сүзтезмәләргә таркатып язарга.

**II вариант.** Дүртенче җөмләне сүзтезмәләргә таркатып язарга.

4. ***Контроль изложение.***

**Күнел түрендә ни ята?**

Без һәркайда — өйдә, мәктәптә, урамда үзара аралашып яшибез. Көндәлек тормышыбызда төрле-төрле хәлләр, вакыйгалар очрап тора. һәр адымда үзебезнең кем икәнлегебезне раслап яшибез. Нинди кеше без? Яхшымы яки начармы, гамьсезме яки игътибарлымы, киң күңеллеме яки игелексезме? Өлкәннәрне хөрмәтли beләбезме, кемгәдер, кыен хәл килеп чыкканда, ярдәм кулын сузабызмы?

... Гадәти бер көн. Автобус килеп туктады, һәм ишектә зур-зур төенчекләр, сумкалар күтәргән апа күренде. Алдагы урыннарның берсендә утырган кыз, керүчегә күз төшереп алды да тәрәзәгә борылды. Янәшә урындыктагы малайлар да апаны күрмәмешкә салыштылар. Авыр сумка тоткан апа як-ягына карангалап торды да, урын тәкъдим итүче табылмагач, әйберен идәнгә куйды. Ниһаять, арттагы рәтләрдән берәү урыныннан кузгалды һәм аны чакырып утыртты.

... Асфальт юл буйлап җиңел машина чаба. Аннан алда кызыл төстәге тагын бер машина җилдерә. Алдагы машина, кинәт кенә юлдан чыгып, зур тизлек белән яр астына — елгага тәгәри. Арттан килүче шоферның бу хәлгә исе дә китми... Тик

янында утырган пассажирлары — ике малай — рульгә чытырдап ябышалар да аны тукталырга мәҗбүр итәләр. Алар, машинадан төшеп, батучыларга ярдәмгә ташланганда, шофер, берни булмагандай, юлын дәвам иттерә.

Беренче вакыйга — тормышыбызда көн саен диярлек очрый торган гадәти хәл. Икенчесе исә — җинаять. Ләкин һәр икесендә дә уртаклык бар. Ул — гамьсезлек. Ә гамьсезлекнең башы нәкъ менә шул көндәлек тормышыбыздагы вак-төякләргә барып тоташа да. Бүген синең күңел күзең авыр әйбер күтәреп каршыңда басып торган кешене иүрмәсә, кеше хәлен анламасаң, иртәгә аннан зуррагын күрмәячәгең көн кебек ачык. Шунысы куанычлы: тормышта гамьсезлек белән янәшә игътибарлылык, игелеклелек яши. Автобуста үз урынын кемгәдер тәкъдим итеп, урынсыз калуны бирәү үзе өчен югалту дип бәяләсә, икенчеләр өчен кешене шатландыра алу — зур табыш.

Бәхеткә, тормышыбызда киң күңелле, игелекле кешеләр күбрәк. Андыйлар соңгы сыныгын иптәшләре белән бүлешүдән тәм табалар. Булганын кеше белән уртаклашырга куркып яшәүчеләргә караганда, алар бәхетлерәк.

Мондый мисалларны бик күп дәвам итеп булыр иде. Бу сөйләгәннәр — көндәлек тормышыбыздагы иң гадәти вакыйгалар. Әмма олы эшләргә юл менә шул гадәти генә тоелган хәлләрдән, шул хәлләрдә кеше булып кала белүдән башлана. *(306 сүз.) (Р.Зариповадан)*

**5. *Җөмләнең иярчен кисәкләре темасына диктант.***

**Яз килә**

Баш очында гына тургай талпына. Аның җыры зәңгәр һавада яңгырап тора да язгы кояш нурларында изрәп яткан кыр өстенә коела. Гөрләвекләр тавышына кушылып, сине хискә күмә, моңа чаклы йоклап яткан күңел кылларыңны тибрәтеп җибәрә.

Ала-кола булып торган басулардан күзгә күренер-күренмәс кенә бу күтәрелә. Урман буена нindидер бер дәһшәтле бик борынгы җанварга охшаган кар сырынтысы сузылып яткан. Урман ягыннан борынга бөре исе, язгы дымлы туфрак исе килеп бәрелә. Биек урман агачларында каргалар кызып-кызып оя ясыйлар. Мәрхәмәтле, игелекле яз барысын да уяткан, һәммәсенә эш тапкан.

Әллә ниткән күңел җилкенүе тоя Гариф. Моңа кадәр тыныч кына типкән йөрәк каядыр ашкына башлый. Шушы көнгә чаклы үз гомеренә туры килгән бер язны да авылда каршылый алмады. Менә нинди икән бит ул туган як язы. (126 сүз)

*М. Хәбибуллиннан*

**Бирем**

2 нче абзацны җөмлә кисәкләре буенча тикшерергә.

**6. *Изложение.***

**Туган мәктәбем**

Унынчы сыйныф укучылары, мәктәптә күптән килә торган гадәт буенча, бәйрәм көненә багышланган кичәгә спектакль әзерлиләр иде. Мондый кичәләр бер традиция булып киткәнлектән, аңа мәктәпнең барлык элекке укучылары катнашырга тырыша, килә алмаганнары хатлар, телеграммалар җибәрәләр. Шуңа күрә соңгы көннәрдә телеграмма ташучылар мәктәп юлыннан өзелмәде. Алар берьюлы бишәр-алтышар телеграмма алып киләләр. Мәскәүдән, Ленинградтан, Киевтан, Барано-вичидан, Одессадан, Владивостоктан — кайдан гына юк ул телеграммалар! Иптәшләр бәйрәмгә катнаша алмаулары өчен кайгыралар, ләкин бу көнне алар, кайда гына булсалар да, үзләрен тәрбияләп үстергән, кеше иткән кадерле мәктәпләрен, хөрмәтле укытучыларын сөеп искә алачакларын белдерәләр.

Спектакль иртәгә билгеләнгән булса да, бүтән шәһәрләрдән һәм районнардан килгән кунаклар мәктәпкә бүген үк җыела башладылар. Кайчандыр шушында укыган, ә хәзер кайсы укытучы, кайсы инженер, кайсы агроном, кайсы врач, кайсы очучы булып өлгергән дәү абыйлар, дәү апалар, укучы балаларны шаккатырып, сыйныф бүлмәләренә кереп йөрделәр, парталардан, тәрәзә төпләреннән, кара такта кырыйларыннан үзләренә генә билгеле булган нindидер тамгалар табып, бер-берләренә күрсәттеләр, көлештеләр, тәрәзәләрдән үрелеп, каядыр тышка карадылар, матур оранжереяләргә охшаган күз явын алырлык чәчәкләр, мәңге яшел үсемлекләр белән бизәлгән озын, якты коридорларда озак-озак сөйләшеп йөрделәр. Кайберләре, сабакларын өйрәнмәгән малайлар шикелле, оялып кына, парталар артына да кереп утырдылар. (182 сүз)

*Г. Әпсәләмовтан*

**Искәрмәләр**

1. *Текстны контроль изложение өчен файдаланырга мөмкин.*
2. *Барановичи, оранжерея сүзләрен тактага язып куярга.*

**Бирем**

*Бергәләп план төзергә.*

7. ***Җөмлә кисәкләре темасына диктант***

**Миңсылу**

Яшь булуына да карамастан, ул эшләрнең үзәгендә Миңсылу бөтерелә. Иң әүвәл, таң атар-атмас борын, йөгерә-йөгерә су ташый, өйгә җылы бирә. Кая карама, бөтерчектәй ул бөтерелә. Өйгә дә күз бәйләнгәч кенә керә.

Анда да тын алып чак кына ял итү юк. Тез арасына гөбене алып, шундый итеп май яза, гомер буе аның белән генә шөгыльләнгән диярсең.

Мәшәкать белән ярты кышның үтеп киткәне сизелми дә калды. Иргали, ит ише әйберләргә югары бәяне базар үзе билгеләгән бер чорны туры китереп, калага җыена башлады.

Көтелгән көн килеп җитте. Сыер суярга кеше чакырды. Алар янында йомыш йомышлап, кая кушсалар шунда йөге¬реп, җиңел сөяк Миңсылу гына бөтерелде: кайнар су, сөлге, табак, ләгән ише әйберләр алып чыкты. Өйдәге хатын-кызлар да җаваплы эш башкардылар. Бер тәпән сары май кайнаттылар, ике тәпәнгә атланмай тутырдылар. Тәпәннәрнең авызлары кояш күзенә җәеп агартылган кершән кебек ак киндерләр белән томалап бәйләнде. (138 сүз)

*М. Хәсәнов*

7***. Изложение.***

**Хөрмәт — матурлык сакчысы.**

Мәктәп тирәсен яңа койма белән әйләндереп алгач, укучыларның күңелләре тагын да  күтәрелеп китте. Яшелчә утыртканда да, түтәлләргә су сипкәндә дә алар

бертуктаусыз шул турыда гына сөйләштеләр:

—Безнең мәктәп коймалары әллә каян балкып күренеп тора хәзер.

—Бакчабыз да матурланып киткән кебек.

—Ишегалдын чирәм дә каплар әле.

Чыннан да, кояш үзенең җылы нурларын сипкән саен, мәктәп бакчасы да, ишегалды да күзгә күренеп ямьләнә барды, яшел төскә күмелде. Укучылар җәй көне дә мәктәпне онытмадылар. Аларның әле бер, әле икенче төркеме бакчада эшләп йөрде. Ишегалдының төрле почмакларында үскән чүп үләннәрне йолкып ташладылар.

Ләкин, берсеннән-берсе яктырак хыяллар белән эшләп йөргән укучыларның кәефен кырып, көтелмәгән бер хәл булып алды. Бакчага керүгә аһ иттеләр. Җимерелгән түтәлләр өстендә эзләр ярылып ята. Тырышып үстергән кишер, кыяр, помидор үсентеләре тапталган, сындырылган... Барысын да яңадан тәртипкә китерү өчен, тагын күпме көч түгәргә туры килде.

Кичтән биредә шушы ук мәктәптә укучы малайлар рәхәтләнеп уйнап йөргәннәр. Берничә малайның ваемсызлыгы аркасында никадәр хезмәт җилгә очты.

Без һәммәбез дә шулай башкалар эшләгән эшкә битараф калсак, безнең үз хезмәтебезне дә шундый ук бәя көтәргә мөмкин ич. Син яңа гына юып чыккан идәндә туганнарың аяк киемен салмый йөри, ди. Бер дә күңелле түгел, шулай бит.

Тәрбияле, әдәпле кеше бервакытта да башкалар хезмәтенә бармак аша карамый. Бары тик халыкның бердәм хезмәте һәм бер-берлзренең хезмәтенә ихтирамы нәтиҗәсендә генә муллык һәм матурлык туа.

Минем шундый хәлгә дә очраганым бар. Җәйге матур көннәрнең берсендә бер төркем кеше табигатькә чыкты. Алар үзләре белән мәктәп яшендәге балаларын да ияркәннәр. Су буендагы матур аланлыкка ял итәргә туктадылар. Бераздан малайлар һәм кызларның кайберләре якындагы печән кибәннәре янына йөгерделәр, шунда качышлы уйнарга, өстенә менеп сикерергә, шуарга тотындылар. Өлкәннәр алар янына килеп җитеп кисәтү ясаганчы, печән кибәннәре җир белән тигезләнгән иде.

Биредә дә малайлар һәм кызларның, бары тик уен белән генә мавыгып, башка нәрсә турында уйламаулары күренә. Аларга бу уенньщ начар булуын,

шуның белән күпме кешенең хезмәте юкка чыгаруларын аңлатсаң, үзләренең дә исләре китәр иде, мөгаен.

Үзебез турында тагын бер кат уйланып карыйк әле. Башкарган эшләребезгә дөрес бәя бирә беләбезме? Әгәр юк икән, әйдәгез, кеше булдырган матурлыкны аңлый һәм саклый белергә бүгеннән үк өйрәник, дуслар! *(338 сүз.)*

*(Х. Хаҗиповтан)*

8.***Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре темасына диктант.***

**Лагерьда Сабантуй**

Иртәгесен кызарып кояш чыкты. Табигате дә әллә сизә инде? Сабан туена нинди матур көн! Иртәнге аш, иртәнге линейка әллә булды, әллә юк, аңа игътибар итүче булмады. Бары тик сабан туе ачылуын көтәбез. Сәгать тугыз. Шат йөзле балалар мәйданчыкны уратып алдылар. Алдан ук әзерләнгән озын эскәмияләрдә безнең әти-әниләр, әби-баб.айлар утырган. Мәйдан уртасында — озын колга, ә аның очында — кызыл башлы борынгы сөлге. Мин моны беренче тапкыр күрәм. Мәйдан алдында — зур өстәл. Анда җиңүчеләргә бүләкләр куелган.

Менә мәйдан уртасында Бикнур абый пәйда булды. Кулында — сырлы таяк. Бу чүлмәк ватарга инде. Ул безне сабан туе ачылу белән котлады. Без дәррәү кул чаптык.

Ул бүгенге көннең программасы белән таныштырды. Жюри әгъзалары үз урыннарына килеп утырдылар. (110 сүз)

*Р. Низамовадан*

9. ***Гади җөмлә төрләре темасына диктант.***

**Яхшы укучы хур булмый**

Нарат җиләкләре шулкадәр күп, шулкадәр эре, тәгәрәп-тәгәрәп үскәннәр. Зөфәр аларның иң эре һәм иң кызылларын сайлап җыйды. Менә аның өч бүлемле кыр сумкасы туп-тулы булды.

Шуннан соң Зөфәр кайту ягына борылды. Бераз баргач, адашканын сизде. Әйе, юлсыз, сукмаксыз кара урманда адашып калуың бик тиз шул. Юан карт

агачлар серле тынлыкка чумып утыралар. Аларның мүкләнеп беткән кабыклары йөрәккә курку сала.

Зөфәр үзен бик тиз кулга алды. Көньякның да, төньякның да кайда булуын билгели ала бит ул. Агач ботакларына карап билгеләргә мәктәптә өйрәттеләр лә аларны. Зөфәр ялгызрак утырган агачларга күз салды. Һәркайсының бер ягында ботаклары сирәгрәк тә, зәгыйфь тә. Ә икенче ягында куе һәм озын булып үскәннәр. Димәк, көньяк шул якта. Малай җиңел сулап куйды һәм алга атлады.

(114 сүз)

*Л. Ихсановадан*

**Бирем.**

**Соңгы кызыл юлны җөмлә кисмәкләре һәм сүз төркемнәре буенча тикшерергә**

10. ***Контроль изложение*** **.**

**Бурыч**

Сәгать алты тулар-тулмас иртәнге прогулкага чыгып барганда, күрше квартирага звонок биреп торучы карчыкка юлыктым. Звонок төймәсе шактый биектә, әбинең буе тәбәнәк кенә: ул, аяк очларына басып, өскә үрелгән. Язгы пальто өстеннән бөркәнгән ак шәле җилкәсенә җыерылып төшкән. Карчык, кулын звонок төймәсеннән I алмый гына, миңа текәлеп карап куйды. Йөзе борчулы, күз карашында ниндидер өметсезлек, аптыраш сизелә иде. Болай да ябык, җыйнак гәүдәсе борчудан куырылып калган кебек тоела.

Әбигә күршеләремнең бер генә атна элек ялга китүләрен әйттем. Ул, хәвефләнеп, ни әйтергә белми тотлыгып калды. Аның тәмам өметсезлеккә төшүен күреп, кызганып куйдым. «Бик кирәк идемени соң алар?» — дим. Карчык баскан җирендә таптанып алды, авыр сулады. «Кирәк иде шул, бәбкәм, бик кирәк иде. Өченче килүем инде. Мунчага барганда, акчамны онытып калдырып, Хәбирәдән 25 тиен акча алып торган идем. Шуны бирәсем бар иде»,— ди. «И әби, шул 25 тиен артыннан йөрмәсәң инде,— дим,— әллә ни зур акча түгел! ич!»

Карчык миңа ялт кына карап алды. Сүзләремне ошатмавы шундук йөзенә

чыкты. «Бирәчәкнең зурысы-кечесе юк анның, бала. Олы кешегә андый бирәчәк белән яшәү дөрес түгел. Үлеи-нитеп китсәм, өстемдә' кала ич!» — диде. «Алайса, калдыр сон миңа 25 тиененңне, алар кайткач, кертеп бирермен»,— дим.

Әбиемнең йөзе балкып китте, җыерчыклары язылды. Ул, кире уйламасын тагын дигәндәй, миңа ашыгып тиеннәрен сузды. «И, балам, игелекле кеше икәнсең, рәхмәт яугыры, тагын ничекләр килермен дип хафаланган идем. Рәхмәт, балам, аягың-кулың сызлаусыз булсын».

Әбинең өстеннән тау төштемени! Ул ашыга-кабалана ишектән чыгып китте. Бурычыннан арынган әбинең эчке бер нур белән балкыган йөзе, җете ак челтәр шәле күз алдымда озак торды. (244 сүз)

(Р. Хафизовадан)

**11. Арадаш аттестация эше.**

**Шаулагыз, имәннәр!**

Мин акрын гына урман эченнән атлыйм. Урмандагы һәр агач үз уена,үз моңыначумган. Карт имәннәр салмак кына шаулыйлар. Җил имән очларына кагыла.Имән – тарихчы ул. Имән – урманның тарихукытучысы. Юкә, каен, миләш – җыр, әдәбият, рәсемукытучылары. **Өрәңге кем?** Белмәссең. Ихтимал, ул – физиктыр. Каты, конкрет, төгәл, эмоцияләр белән исәпләшми.

Имән – тарихчы, монысы бәхәссез. Әнә карт имәннәр нидер сөйлиләр. **Сөйләгез, агачлар, сөйләгез!** Бу якның халкы газаплы сугыш елларын даниләрк үрде? Халыкның аһ-зарлары кайларга сеңде? Сезнең төпләрегездә өелеп яткан чикләвекләрне кемнәр җыйды? Кемнәр, рәхимсез кышкы көннәрдә, имән чикләвегенең күмәчен ашап, ач үлемне җиңделәр?

Офык чистарды, имәннәр әллә нинди шом белән, әллә нинди ныклык, куәт белән шауладылар да шауладылар. Шаулагыз, имәннәр, тыныч тормышның беренче кышына мәдхияҗ ырлагыз! Халкыма иминлек теләгез! (118 сүз)

**Бирем:**

1. **Ия белән хәбәр арасына сызык куелган җөмләләрнең баш кисәкләрен билгеләргә.**

2. **Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләләргә тулы синтаксик анализ ясагыз.**
3. **Аерымланган хәл булган җөмләне табып, җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез.**
4. **Тексттан эндәш сүзләрне табып, түгәрәк эченә алыгыз.**